Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Мәмәт авыл җирлеге башлыгы

# КАРАРЫ

07 ноябрь 2019 ел N 3

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Мәмәт авыл җирлеге
Мәмәт авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын
билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 24 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл җирлегенең Мәмәт авылында Калинин, Куйбышев, Көньяк урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2019 елның 24 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл җирлегенең Мәмәт авылында Октябрь, Ленин, Шәйдуллин урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2019 елның 24 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл җирлегенең Мәмәт авылында Совет, Мириханов урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мәмәт авыл җирлегенең Мәмәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: торак пункт юлларын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Халык җыены этапларын Мәмәт авылы мәдәният йорты бинасында, түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы Әлмәт районы, Мәмәт авылы, Совет урамы, 3 нче йортта уздырырга.

5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл җирлегенең Мәмәт авылында сайлау хокукына ия булган авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

6. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Мәмәт авылы, Совет урамы, 1 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Мәмәт
авыл җирлеге башлыгы — И.М. Зөбәерова